РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

27 май 2020 ел 3 номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Адав-Толымбай авыл җирлегенең генераль
план проекты буенча гавами (ачык) тыңлаулар
билгеләү турында

Адав-Толымбай авыл җирлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукларын тәэмин итү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясына, Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Уставына таянып

КАРАР БИРӘМ:

1. Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 29 июнендә 9:00 сәгатькә Адав-Толымбай авыл мәдәният йорты бинасында (ТР, Буа районы, Адав-Толымбай авылы , Совет урамы, 19 йорт) билгеләргә.

2. Генераль план проектында булган материаллар белән танышырга мөмкин:

- текст һәм график өлеше белән Буа муниципаль районы сайтында: http://buinsk.tatarstan.ru/
- текст һәм график өлеше белән эш көннәрендә 09.00 дән 18.00 гә кадәр авыл җирлеге хакимияте бинасында.

3. Генераль план проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп, Адав-Толымбай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе бүлмәсен билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга, шулай ук Адав-Толымбай авыл мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Адав-Толымбай авыл
җирлеге башлыгы А.Ф. Әхмәтҗанов